**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАТУН АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

5 август, 2019 ел №201

**«Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Каратун авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 105 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка түбәндәге редакциядәге 3.1 пунктчасын өстәргә:

«3.1) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Каратун авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Каратун авыл**
**җирлеге башлыгы** **Сабирҗанова Р. Р.**